**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**Сапеевского сельского поселения**
**Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы**
**Сэпэй авыл**
**җирлеге Советы**
**БАШЛЫГЫ**

ул. Школьная, д.53В, село Сапеево,
Азнакаевского муниципального района, 423326
Тел. (факс) (8-85592) 44-2-40, факс 44-2-83
Sap.Azn@tatar.ru

Школьная урамы , 53В, Сэпэй авылы
Азнакай муниципаль районы, 423326
Тел. (факс) (8-85592) 44-2-40
Sap.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«01» ноябрь 2019 ел № 2

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлегенең Сәпәй торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Уставы белән, **карар чыгарам:**

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Сәпәй авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2019 елның 12 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә: Совет урамы 1 йорттан 16 йортка кадәр, Тукай урамы 1 йорттан 33 йортка кадәр, Х.Шарапова урамы урамы 1 йорттан 10 йортка кадәр, Г.Хәсәншина урамы 1 йорттан 12 йортка кадәр, Һ.Такташ урамы 1 йорттан 13 йортка кадәр, Казан урамы 1 йорттан 18 йортка кадәр .

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Сәпәй авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2019 елның 12 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә: Мәктәп урамы 1 йорттан 55 йортка кадәр, 1 Май урамы 1 йорттан 22 йортка кадәр, Чапаев урамы 1 йорттан 32 йортка кадәр, А.Алиш урамы 1 йорттан 11 йортка кадәр, Нефтьчеләр урамы 1 йорттан 15 йортка кадәр, Яңа урам 1 йорттан 50 йортка кадәр, Совет урамы 18 йорттан 20 йортка кадәр.

3.Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Сәпәй авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенының беренче этабын уздыру вакыты – 12 ноябрь 2019 ел 10.00 сәг.тән 11.00 сәг.кадәр;
- гражданнар җыенының икенче этабын уздыру вакыты – 12 ноябрь 2019 ел 14.00 сәг.тән 15.00 сәг.кадәр;
- гражданнар җыенының беренче һәм икенче этабын уздыру урыны – Сәпәй авылы, Казан ур. , 19А йорт, Сәпәй авыл мәдәният йорты залы;

4. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2019 елның 6 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Сәпәй авылы, Мәктәп урамы, 53В йорт

- сайлау хокукына ия булган Сәпәй торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләү;
- Сәпәй торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнарның җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 Сәпәй авыл җирлеге Сәпәй торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 350 сум күләмендә үзара салым кертү, 2 төркем инвалидлардан бер тапкыр түләтүне 175 (50%) сумга киметеп һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Сәпәй авылында бәйрәм чаралары үткәрү (бүләк, сувенир продукөиясе сатып алу, “Җиңү көне”, “Сабантуй”, “Халыкара өлкәннәр көне”, “Яңа ел” бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәт күрсәтү);
- Сәпәй авылында юлларны кардан чистарту;
- Сәпәй авылында җәй көне территорияне чабу;
- Мачаклы-Баш авылында һәйкәл кую (коймалар урнаштыру, буяу, агарту, эшләр өчен килешү буенча түләү);
- Сәпәй авылында урам күрсәткечләрен ике телдә ясату һәм урнаштыру.

« РИЗА» «КАРШЫ».

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Сәпәй авылы, Мәктәп ур., 53В йорт, Сәпәй мәдәният йорты, Казан ур.19 адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

7. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Башлык Ф.Г.Галиева